

Шундый исем белән 6 август конне А.С.Пушкин исемендәге паркта Мордовия Республикасы авыллары фольклор ансамбльләренен 1 Республика фестивале vтте. Чарада республикабызнын 17 районнан берничәшәр жыр һәм бию коллективлары һәм Тvбәншәһәр олкәсе Лукоян районы ансамбле катнаштылар. Бәйрәмгә хас кvтәренке кvнел, жыр-кой, милли киемнәрнен матур бизәлеше, катнашучылар йозендә жылы елмаюлар фестивальгә остәмә коч бирде; кояшнын эсселеге бәйрәмдәгедән дә кызу иде. Мона карамастан, берничә сәгать буена парк бер зур концерт залына әверелде. Программа эчтәлекле һәм тыгыз булды. Сәхнәдәге һәрбер коллектив туган телләрендә ата-бабаларыннан килгән авыл жырларын башкарды һәм гореф-гадәт кvренешләреннән эпизодларны кvрсәттеләр. Фестивальне халыкка бvләк итvчеләре, оештыручылары – «Фин-угр халкынын Иделбуе мәдәнияты Үзәге» коммерциясез Ассоциациясе.  Сер тvгел, Мордовиядә һәрвакыт торле милләт халыкларынын дус-тату яшәве, мәрхәмәтле кvршелек монәсәбәтләре буенча ил кvләмендә vрнәк булып тора. Милләтара тынычлык, анлашып яшәv гасырлар буена мирас булып буыннан-буынга кvчә бара. Монда, әлбәттә, республика житәкчелегенен акыллы сәясәт алып баруы да зур роль уйный. Торле милләт халыкларынын гореф-гадәтләренә игътибарлы булу, һәр халыкнын бәйрәмнәрен кvмәкләп vткәрv дуслыкны ныгыта. Шул максатларны кvздә тотып ел саен «Туган авылым жырлый» дигән республикабыз фестивале ел саен vтәчәк.

Парк сәхнәсеннән милли моннарыбыз янгырап торды. Тамашачылар да оялып-тартынып тормады, кушылып жырлады, рәхәтләнеп биеде. Ләмберә районында яшәгән рус, мордва, татар мәдәнияты, милли әйберләреннән торган эчтәлекле кvргәзмәсен Надежда Борисовна тамашачыга тәгъдим итте. Бик арыган кеше биредәге милли ризыклар белән сыйланды, дуслары белән аралашты.

Мордовиянен Ләмберә районында кvпләп татарлар яши. Фестивальдә милли мәдәниятыбызны саклап килгән Татар Свербеевка авылы vзэшчән «Золәйха» ансамбле һәм жырчы Каюм Гани улы Апарин авыл такмаклары-жырлары белән халык кvнеленә хуш килде. Үзенен тарихын узган гасырнын 72нче елларыннан башлап жибәргән Кадошкино районы Большие Поляны «Дуслык» жыр ансамбле милли моннарыбызны саклап калу очен зур тырышлык кvрсәтәләр. Алсу Әнвәр кызы Кильдеева, Альфия Юнир кызы Капкаева, Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева, Рима Зәкәрья кызы Ляпина, Надия Али кызы Капкаева, Светлана Наиль кызы Кильдеева, Наилә Идрис кызы Горчакова, Наилә Хафиз кызы Долотказина, Светлана Шәмил кызы Абаева бу vзэшчән коллектив жырчылары - Иса авылы татар-мишәрләренен визит карточкасы.

Репертуарларынын нигезен халык жырлары, дастаннары, лирик һәм шаян йола kvренешләре тәшкил итә; татар халык ижаты белән бергә, ансамбль эстрада жырларын да яратып башкара. «Дуслык» - kvпторле конкурсларда катнашып республикабыз бvләкләрен яулаган ансамбль. «Туган авылым жырлый» фестивалендә дә kvнелләрне тибрәтерлек иттереп «Авылым койләре»н  башкардылар, авыл мәдәниятынын vсешенә багышланган сцена эпизодын уйнап тамашачыны vзләренә тартып тордылар.
- Эчтәлекле, кызыклы, мавыктыргыч булды бу фестиваль, – дип  Мордовия Республикасы авыллары фольклор ансамбльләренен 1 Республика фестивале турында фикерләре белән уртак-лашты «Дуслык» ансамбле жырчысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева. - Торле милләт вәкилләре милли бизәкле матур костюмнарын киеп, милли койләрен сузулары таныш та, әмма ниндидер буяу тосмере алган яна да булып янгырады. Биредә чәчәкләр бәйләменен һәрбер чәчәге vзенчә ямьле булды. Нәтижәдә, коннен эссе булуына карамастан, унай  эмоцияләр, Грамоталар, Рәхмәт хатлары, катнашучы Дипломнары, истәлекле бvләкләр алып кайттык, диде.

**Наилә Насырова**